**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«14» 06 2024 ел Яр Чаллы №70

Калмия авыл җирлегендә 16:39:130101:10 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Камлия авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, Тукай муниципаль районы Уставы, район Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

**КАРАР БИРӘМ**

1. Калмия авыл җирлегендә 16:39:130101:10 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Шәхси хуҗалык алып бару өчен» төп төрдән «Кибетләр» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2.1. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга (tukay.tatarstan.ru).

2.2. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында бастырып чыгарырга.

3. Билгеләргә:

3.1. үткәрү вакытын: **2024 елның 3 июлендә 14:00 сәгатьтә,** урынын: Калмия авылы, Молодежная ур., 24, Башкарма комитет;

3.2. проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, 203 каб.;

3.3. тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 19 июненнән 2024 елның 3 июленә кадәр кабул ителә.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинны билгеләргә.

5. Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.И. Закиров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН • ТУКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН • СОВЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА • ИНН 1639031685 • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ • ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2024 елның 14.06 70 номерлы карарына кушымта

# ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге тәртип җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарының фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Тукай муниципаль районы халкы тарафыннан язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр **2024 елның 19 июненнән 2024 елның 3 июленә кадәр** түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 каб.

3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

4. Халык тыңлаулары секретаре фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

5. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

6. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

7. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

8. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

9. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.